| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

15 май 2020 ел Буа шәһәре 5-53 номерлы

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2015 елның 13 февралендәге 9-45 номерлы «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында Нигезләмә хакында» (2017 елның 28 апрелендәге 9-19 номерлы карары редакциясендә) карары белән расланган, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә ( алга таба- Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 13 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән документлар конкурс комиссиясенә конкурс үткәрү турында хәбәр басылып чыккан көннән 20 көн эчендә бирелә. Документларны вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә бирү гражданга аларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.».

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча http://buinsk.tatarstan.ru урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа муниципаль районы Башлыгы урынбасары,
Совет рәисе урынбасары И.Ф. Еремеев